**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«06» 03 2020 ел Яр Чаллы ш. № 697

«Театр Олимпы» фестиваль-конкурсын үткәрү турында

«2019-2021 елларга Тукай муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү район комплекслы программасы»н гамәлгә ашыру кысаларында, РФ Президентының 2018 елның 9 маендагы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру турында» 211 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 25 сентябрендәге «Татарстан Республикасында 2020 елны Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгы елы дип игълан итү турында» УП-572 номерлы Указы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсы нигезләмәсен расларга (1 нче кушымта).
2. 2020 елның 25 мартында Түбән Суыксу авылы мәдәният йортында «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсында катнашучыларны бүләкләү тантанасын уздырырга.
3. Чараны үткәрүгә чыгымнар сметасын «Тукай муниципаль районының мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе средстволары хисабына расларга (2 нче кушымта).
4. Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе Э.М. Әхмәтҗановага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л. Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06.03. 697 номерлы карарына 1 нче кушымта

**«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район конкурсын үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге нигезләмә «Театр Олимпы» фестиваль-конкурсын үткәрү тәртибен һәм регламентын билгели.

Фестиваль-конкурс район театр коллективларының мәдәни дәрәҗәсен күтәрү максатыннан үткәрелә.

Конкурсны «Тукай муниципаль районының мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе оештыра.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

Конкурсның максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- балаларга һәм яшүсмерләргә патриотик тәрбия бирү;
- конкурста катнашучылар арасында дустанә һәм иҗади, мәдәни элемтәләр урнаштыру;
- катнашучыларның башкару осталыгы дәрәҗәсен күтәрү, коллективларның һәм режиссерлык-кую эшләренең репертуарын киңәйтү;
- сәләтле һәм талантлы башкаручыларны, коллективларны һәм куючы режиссерларны ачыклау;
- массакүләм мәгълүмат чаралары аша иҗади шәхеснең социаль статусын күтәрү;
- талантлы яшь башкаручыларга ярдәм итү системасын булдыру.

## 3. Конкурсның оештыру структурасы

«Тукай муниципаль районының мәдәният һәм ял үзәге» МБУ барлык театр коллективларының фестиваль-конкурста катнашуын оештыра.

Фестиваль-конкурсны уздыру һәм нәтиҗәләр ясау өчен оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара:

- конкурсның жюри составын раслый;
- конкурсны әзерләү һәм үткәрү эшен планлаштыра һәм координацияли;
- конкурсның оештыру мәсьәләләрен хәл итә;
- конкурс үткәрү турында хәбәр итә;
- конкурсның шартларын, критерийларын эшләүне, аларның үтәлешен бәяләүне оештыра.

## 4. Конкурста катнашучылар

Фестиваль-конкурста Тукай муниципаль районының мәдәният учреждениеләре базасында эшләүче театр коллективлары, халык театрлары, спутник коллективлары, студияләр, үзешчән иҗат коллективлары катнаша.

Яшь категорияләре:

- мәктәпкәчә яшьтәге балалар: 6 яшьтән 7 яшькә кадәр;
- башлангыч мәктәп: 7 яшьтән 12 яшькә кадәр;
- мәкәтәп укучылары: 12 яшьтән 18 яшькә кадәр;
- яшьләр: 18 яшьтән 36 яшькә кадәр;
- өлкәннәр: 36 яшьтән 55 яшькә кадәр;
- олы яшьтәгеләр: 55 яшьтән өлкәнрәк.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

Фестиваль-конкурс 2020 елның 6 мартыннан 2020 елның 25 мартына кадәр узачак. Ике этапта үткәрелә.

Беренче этап - зона этабы, Тукай муниципаль районы авыл мәдәният йортлары базасында үткәрелә. Авыл мәдәният йортлары «1941 - 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район конкурсының рекламасын оештыра.

Фестиваль-конкурста катнашучылар (яшьләр һәм өлкәннәр) жюри игътибарына татар һәм рус телләрендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган тулы актттагы әсәр тәкъдим итә.

Балалар коллективлары тематикага туры килә торган, дәвамлылыгы кимендә 20 минут (30 минуттан да артык түгел) булган бер спектакль әзерлиләр.

Конкурста халык театрлары һәм аларның спутник коллективлары катнашу мәҗбүри!

Икенче этап - финал туры һәм фестиваль-конкурста катнашучыларны тантаналы бүләкләү - 2020 елның 25 мартында узачак.

Фестиваль-конкурста катнашучылар әлеге Нигезләмәнең барлык шартларын да үтәргә тиеш. Үткәрү урыны һәм вакыты өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

## 6. Бәяләү критерийлары

- әсәр темасын тулысынча ачу ;
- артистлык, спектакльнең ачылышы һәм күңеллелеге;
- башкару дәрәҗәсе;
- дикциянең тәэсирлелеге;
- спектакльнең катлаулылыгы дәрәҗәсе;
- башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә репертуарның туры килүе.

## 7. Фестиваль-конкурста жюри

Жюри составы фестиваль-конкурсны оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

Жюри составын рәис җитәкли.

Жюри башкаручыларны 10 баллы система буенча бәяли.

Әгәр жюри әгъзасы фестиваль-конкурста катнашучының укытучысы булса, ул үз катнашучысын тыңлау нәтиҗәләрен бәяләгәндә тавыш бирми. Фестиваль-

конкурста катнашучылар өчен җыелган балларны санаганда, калган жюри әгъзаларының баллары суммасына аларның уртача баллы өстәлә.

Урыннарны бүлү уртача балл нигезендә башкарыла.

Конкурс чыгышлары буенча фикер алышуның нәтиҗәсе булып жюри әгъзаларының утырыш беркетмәсе тора. Беркетмә нигезендә фестиваль-конкурста катнашучы дипломнары тапшырыла.

Жюри түбәндәге хокукларга ия:

- катнашучыларны, режиссерларны, театр коллективлары җитәкчеләрен махсус дипломнар һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләү;
- барлык призлы урыннарны да бирмәү;
- бүләкләнүчеләрнең билгеләнгән саны чикләрендә урыннарны бүлү;
- финал-тантаналы бүләкләү тантанасында чыгыш ясау өчен катнашучылар исемлеген төзү.

Жюри карары соңгы нәтиҗә булып тора һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

## 8. Конкурска йомгак ясау

Җиңүчеләр бүләкләнә: Һәр яшь төркемендә Гран-при, I, II һәм III урыннар һәм түбәндәге номинацияләр буенча катнашучы дипломнары белән:

- «Иң яхшы хатын-кыз роле өчен»;
- «Иң яхшы ир-ат роле өчен»;
- «Иң яхшы яшь актер» номинациясе өчен;
- «Икенче пландагы иң яхшы балалар роле өчен»;
- «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле өчен»;
- «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле өчен»;
- «Иң яхшы режиссерлык осталыгы өчен».

Фестиваль-конкурс нәтиҗәләре Вконтакте социаль челтәрендә: https://m.vk.com/kulturnaya_ploshadka_tmr «Культурная площадка ТМР» һәм «Якты юл» («Светлый путь») газетасында урнаштырылачак.

## 9. Гаризалар бирү тәртибе

Фестиваль-конкурста катнашу өчен тапшырыла:

Билгеләнгән формадагы гариза (Нигезләмәгә 1 нче кушымта). Кулдан тутырылган гаризалар кабул ителми.

Гаризалар 2020 елның 6 мартына кадәр электрон адрес буенча: Kultura.Tuk@tatar.ru яисә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, каб. 113.

Элемтә өчен телефон: 8 (8552) 70-13-42 - Хурамшина Ализа Дилшат кызы.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык тутырырга (имзаларга) кирәк (Нигезләмәгә 2 нче кушымта).

Кандидатларга гариза белән бергә җибәрелгән барлык материалларның күчермәләрен сакларга кирәк.

Катнашучыларны теркәгәндә гаризаларны дөрес һәм грамоталы тутыру мәҗбүри шарт булып тора. Катнашучылар бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсы нигезләмәсенә 1 нче кушымта

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсында катнашу өчен

**ГАРИЗА**

| | |
|---|---|
| Әсәрнең исеме | |
| Авторы | |
| Регламент | |
| Режиссерның Ф.И.А.и. | |
| Коллективның исеме | |
| Учреждениенең, оешманың исеме | |
| Адрес (авыл җирлеге, поселок/авыл) | |
| Телефон | |
| E-mail | |
| Катнашучылар исемлеге:<br>Ф.И.А.и. /туган елы/эш урыны яки белем бирү учреждениесе | 1.<br>2.<br>3… |

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсы нигезләмәсенә 2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык

Мин, (Ф.И.А.и.)

1.
2.
3.
4.
5.

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсын оештыру һәм үткәрү максатында, түбәндәге шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр (операцияләр) башкару), шул исәптән җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), иясезләндерүне дә кертеп, ризалыгымны белдерәм:

- фамилия, исем, атасының исеме;
- туган көн;
- вазыйфа;
- эш урыны.

Оештыру комитеты тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртү (кәгазь чыганакларда; шәхси мәгълүмат системаларында һәм автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шулай ук катнаш ысул белән) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хезмәт Кодексының 14 бүлеге таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш.

«Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсының нигезләмәсе һәм анда катнашу шартлары белән таныштым:

Дата ____________________
Имза ____________________

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ___ ______________ _____ номерлы карарына 2 нче кушымта

**«2019-2021 елларга Тукай муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү» район комплекслы программасын гамәлгә ашыру кысаларында 1941 - 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәм Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Театр Олимпы» III район конкурсының сметасы**

| № | | Чыгымнар исеме | Саны | Үлчәү берәмлеге | Бәясе | Суммасы (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 1 | Рамкалар (7 - номинацияләр, 18 - призлы урыннар, 36 - режиссерларга Рәхмәт хатлары) | 61 | данә | 65,00 | 3 965,00 |
| 2. | 1 | Бүләкләр: 1 урын | 6 | данә | 3000,00 | 18 000,00 |
| | 2 | 2 урын | 6 | данә | 2000,00 | 12 000,00 |
| | 3 | 3 урын | 6 | данә | 1000,00 | 6 000,00 |
| | 4 | Гран-при | 1 | данә | 3 000,00 | 3 000,00 |
| 3. | 1 | Җиңүчеләргә кубоклар: «Динара 23 см» 1 урын | 6 | данә | 500,00 | 3 000,00 |
| | 2 | 2 урын | 6 | данә | 500,00 | 3 000,00 |
| | 3 | 3 урын | 6 | данә | 500,00 | 3 000,00 |
| 4. | 1 | «Йолдыз» сыны номинацияләр буенча: «Иң яхшы хатын-кыз роле өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 2 | «Иң яхшы ир-ат роле өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 3 | «Иң яхшы яшь актер» номинациясе өчен | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 4 | «Икенче пландагы иң яхшы балалар роле өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 5 | «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 6 | «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| | 7 | «Иң яхшы режиссерлык осталыгы өчен» | 1 | данә | 500,00 | 500,00 |
| 5. | 1 | Чәчәк бәйләме | 61 | данә | 350,00 | 21 350,00 |
| **БАРЛЫГЫ:** | | | | | | **76 815,00** |

БАРЛЫГЫ: 76 815,00 (житмеш алты мең сигез йөз унбиш сум 00 тиен)